ГЛАВА
Бимекого сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Бима авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.11.2025 Бима авылы № 6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы «Бима авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең Мадык
торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мадык торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 8 декабренә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:
2.1.«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мадык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, (I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә

һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, кулланyга ризамы?

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар кўрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар сатып алу һәм алмаштыру, хезмәт килешүе буенча электрикка түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Мадык торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү, чишмөзекләндерү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

«РИЗА» «КАРШЫ»

2.2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының» Бима авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Мадык торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 31.10.2025 №1 карарны гамәлдән чыгарырга ризамы? «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары үз көчләрен югалткан дип танылды

"КАРШЫ" «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Мадык авылы, Киров урамы, 20нче йорт адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Э.И. Михайлов